# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Татарстан Республикасы Җир кодексына**
**үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2012 елның 24 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Җир кодексына (2005 елның 18 гыйнварындагы 4-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 8 (II өлеш); 1999, № 8 (I өлеш); 2005, № 1 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2006, № 7 (I өлеш); 2007, № 1 (I өлеш), № 4; 2008, № 5 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (III өлеш); 2010, № 11; 2011, № 11 (I өлеш); 2012, № 3, № 5 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 19 статьяның 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:
"Татарстан Республикасына федераль милектән түләүсез тапшырылган.";

2) 20 статьяның 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:
"муниципаль милеккә федераль милектән түләүсез тапшырылган.";

3) 21 статьяның 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле $5^1$ пунктча өстәргә:
"$5^1$) дәүләт яисә муниципаль милектәге җирләрдән – федераль законда каралган очракларда торак-төзелеш кооперативларына;";

4) 31 статьяның 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: "Әлеге гариза дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге (алга таба – күпфункцияле үзәк) аша да бирелергә мөмкин.";

5) $32^1$ статьяда:

а) 9 пунктның икенче абзацына "бирелергә мөмкин" сүзләре алдыннан "турыдан-туры җирле үзидарәнең вәкаләтле органына йә күпфункцияле үзәк аша да" сүзләрен өстәргә;

б) 16 пунктның икенче абзацына "бирелергә мөмкин" сүзләре алдыннан "турыдан-туры җирле үзидарәнең вәкаләтле органына йә күпфункцияле үзәк аша да" сүзләрен өстәргә;

в) 18 пунктта "гаризаны алар җирле үзидарә органына биргән көннән" сүзләрен "гариза җирле үзидарә органына кергән көннән" сүзләренә алмаштырырга;

6) 44 статьяның 2 пунктындагы икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Милеккә җир кишәрлеген бирү турындагы яисә җир кишәрлеген милеккә бирүдән баш тарту турындагы карар тиешле җир кишәрлекләрен бирү хокукына ия булган башкарма хакимиятнең вәкаләтле органына яисә җирле үзидарә органына арендатор тарафыннан язма рәвештә яисә, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләреннән файдаланып, электрон документ рәвешендә гариза бирелгән көннән соң 30 көн эчендә кабул ителергә тиеш. Әлеге гариза күпфункцияле үзәк аша да бирелергә мөмкин.".

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2013 елның 12 гыйнвары
№ 2-ТРЗ